**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

06.10.2022 № 325

**Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча ведомствоара эш төркеме составына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2013 елның 29 мартындагы 161 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 31 гыйнварындагы 103 номерлы, 2014 елның 31 октябрендәге 632 номерлы һәм 2015 елның 14 ноябрендәге 671 номерлы, 2017 елның 17 апрелендәге 235 номерлы, 2017 елның 21 августындагы 511 номерлы, 2018 елның 13 апрелендәге 154 номерлы, 2020 елның 17 апрелендәге 146 номерлы, 2020 елның 21 декабрендәге 374 номерлы һәм 2021 елның 16 февралендәге 89 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – эш төркеме) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эш төркеме составыннан А.М. Терентьевны чыгарырга;

эш төркеме составына кертергә:

эш төркеме рәисе урынбасары итеп раслап, Мөхәрләмов Руслан Роберт улын – Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесен;

Сәгыйтова Гүзәл Рәмзил кызы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча);

эш төркеме әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.М. Заиканың – «Татарстан Республикасы прокурорының беренче урынбасары (килешү буенча)»;

В.Е. Козловның – «Педагогика, психология һәм социаль мәсьәләләр институты» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры (килешү буенча)»;

Л.В. Сәгыйтованың – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесенең этнологик тикшеренүләр бүлеге әйдәүче фәнни хезмәткәре (килешү буенча)»;

В.М. Самойленконың – «Рус Православие Чиркәвенең Казан епархиясе Казан православие дини семинариясе» дини оешмасы – дини югары белем бирү мәгариф оешмасы ректоры, протоиерей (килешү буенча)»;

Т.Җ. Сөләймановның – «Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры»;

Р.Р. Хәйретдиновның – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры (килешү буенча)»;

М.М. Хухунашвилиның – «Казан шәһәре Вахитов районының «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» мәгариф үзәге муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры, Казан шәһәренең «Сиони» грузин милли-мәдәни мохтарияте» җирле иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе (килешү буенча)»;

Д.Ф. Шакировның – «Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисенең беренче урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)»;

К.Г. Яковлевның – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесе, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы рәисе урынбасары (килешү буенча)».

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН